**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422870, ТР Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

---

2019 елның 14 декабре 435№

**Әлки муниципаль районы территориясендә эпизоотиягә каршы даими әзерлекле җыелма мобиль отряд төзү турында**

1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы «Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законы, 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы «Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» Федераль закон нигезендә, кеше һәм хайваннар өчен уртак булган аеруча куркыныч авырулар чыганагына каршы көрәш һәм профилактика максатларында Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлки муниципаль районы территориясендә эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряд оештырырга.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

1 нче кушымта нигезендә Әлки муниципаль районының (алга таба - Отряд) эпизоотиягә каршы даими әзерлекле җыелма мобиль отряды турында Нигезләмәне;

2 нче кушымта нигезендә Отрядның оештыру-штат структурасын;

3 нче кушымта нигезендә отрядның күләме буенча составын;

4 нче кушымта нигезендә отряд составына кертелә торган автомобиль техникасы исемлеген;

5 нче кушымта нигезендә Отрядның төркем командирларына эш һәм эштә булмаган вакытта хәбәр итү схемасын;

6 нчы кушымта нигезендә район дәүләт ветеринария берләшмәсенең Отряд төркемнәренең командирларына хәбәр итү һәм җыю буенча кизү торучысының инструкциясен.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Әлки муниципаль районы буенча авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгына йөкләргә.

**Әлки муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **И.В.Йосыпов**

Гнеденков Ю. А. 8(84346) 2-02-04

**Расланган**
**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесенең**
**20___ елның ____ _________ ___ номерлы Карары белән**

## Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряды турында

## Нигезләмә

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Әлеге Нигезләмә Әлки муниципаль районы территориясендә эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отрядын (алга таба 4 Отряд)оештыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен билгели.

1.2 Отряд штаттан тыш формалашу булып тора һәм Әлки муниципаль районында кеше һәм хайваннар өчен уртак булган аеруча куркыныч авырулар чыганагына каршы көрәш һәм профилактика максатларында Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары нигезендә төзелә һәм сәбәбе хайваннарның аеруча куркыныч авырулары булган биологик-социаль характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу һәм килеп чыгу куркынычы белән бәйле мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнә.

1.3 Отряд үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы "Ветеринария турында" Россия Федерациясе Законына, 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы "Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында" Федераль Законына, Россия Федерациясенең Баш дәүләт ветеринария инспекторы тарафыннан расланган биологик калдыкларны җыю, утильләштерү һәм юк итү буенча ветеринария-санитария кагыйдәләренә, кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең башка норматив документларына, кеше һәм хайваннар өчен уртак булган куркыныч авыруларны профилактикалау һәм бетерү турында Әлки муниципаль районы башлыгы боерыклары һәм карарлары, Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары һәм боерыклары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә нигезләнә.

1.4 Отряд «Әлки район дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ, Әлки районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының бүлекчәсе, шулай ук "Базарлы Матак үзәк район хастаханәсе" ДАССО, «Әлки коммуналь челтәрләре» ҖЧҖ, «Кызыл Шәрык Агро» АҖнең Әлки филиалы, «Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФБССОның Нурлат районындагы филиалы һәм җирле үзидарә органнары вәкилләре һәм белгечләреннән формалаша.

1.5 Отрядның шәхси составы кирәкле профилактик вакцинацияне вакытында үтәргә тиеш.

### 2. ОТРЯД БУРЫЧЛАРЫ

Гнеденков Ю. А. 8(84346) 2-02-04

2.1. Отряд кеше һәм хайваннар өчен уртак булган аеруча куркыныч авырулар чыганакларына каршы профилактика һәм көрәшү максатларында төзелә, һәм сәбәбе хайваннарның аеруча куркыныч авырулары булган биологик-социаль характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу һәм килеп чыгу куркынычы белән бәйле мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнә.

2.2. Отрядның бурычлары этаплап билгеләнә:
беренче этап-авыруның барлыкка китерүче төрен (яки хайваннар авыруының һәм үлеменең сәбәпләрен билгеләгәнчегә кадәр);
икенче этап-авыруны барлыкка китерүче төрне ачыклганнан һәм ахыргы диагноз куелганнан соң.

2.2.1. Беренче этапта Отрядның бурычлары:
- ветеринария һәм медицина разведкаларын гамәлгә ашыру;
- эпидемиология һәм эпизоотик хәлне бәяләү;
– контактлы, зәгыйфьләнгән һәм авыру хайваннарны (алга таба-авыру хайваннар) читләштерү;
- үлгән, клиник авыру хайваннардан патологик материал алу;
- вирусологик тикшеренүләр һәм дифференциаль диагностика уздыру өчен махсуслаштырылган лабораторияләргә пробаларны китереп тапшыру;
- җиһазларны, инвентарьларны һәм биналарны хайваннарны читләштергәннән соң агымдагы һәм йомгаклау дезинфекциясен үткәрү;
- биналарны һәм территорияләрне механик рәвештә чистарту.

2.2.2. Отрядның икенче этаптагы бурычлары:
- карантин зонасында үткәрү режимын тәүлек буе контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;
- карантин зонасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү;
- карантин зонасында урнашкан халык арасында профилактик һәм эпидемиягә каршы чаралар үткәрү;
- эпизоотик авыру чыганагында барлык авыру хайваннарны аулау һәм сую;
- үлгән хайваннарны транспортировкалау һәм утильләштерү (юк итү) урыннарына ташу;
- үлгән хайваннар үләксәләрен утильләштерү;
- эпизоотик авыру чыганагын бетерүдә катнашучы Отрядның шәхси составын һәм башка затларны санитар эшкәртү;
- бер тапкыр кулланыла торган саклану чараларын юк итү;
- дезинфекция буенча барлык чаралар комплексын үткәрү;
- хайваннардагы аеруча куркыныч авыруларны бетерү максатларында үткәрелә торган чараларның кирәклеге һәм максатчанлыгы турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша халыкка хәбәр итү.

## 3. ОТРЯД БҮЛЕКЧӘЛӘРЕНЕҢ ОЕШТЫРУ СТРУКТУРАСЫ, БУРЫЧЛАРЫ ҺӘМ ҖИҺАЗЛАНДЫРЫЛУЫ

3.1. Отрядның командиры һәм шәхси составы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән билгеләнә. Отрядның командиры булып «Әлки район дәүләт ветеринария берләшмәсе»ДБУ башлыгы тора.

3.2. Отряд төп бүлекчәләрдән һәм тәэмин итү бүлекчәләреннән тора.

Гнеденков Ю. А. 8(84346) 2-02-04

Төп бүлекчәләр:
- ветеринария разведкасы төркеме;
- хайваннарны тоту һәм үтерү төркеме;
- утильләштерү төркеме;
- дезинфекция төркеме.

Тәэмин итү бүлекчәләре:
- медицина һәм эпидемиология разведкасы төркеме;
- үткәрү режимын тәэмин итү төркеме;
- җәмәгать тәртибен саклау төркеме;
- табиб-шәфкать туташлары бригадасы;
- янгын бүлекчәсе;
- санитар эшкәртү пункты.

3.3. Ветеринария разведкасы төркеме үлгән (авыру) хайваннар ачыкланган (табылган) урыннарга чыгып, патологик материал сайлап алуны (Инструкция нигезендә кан, патологик материал һәм биоматериалны сайлап алу), аны махсуслаштырылган лабораториягә илтүне (тикшерү өчен пробалар бирү тәртибе нигезендә) һәм үлгән хайваннарны ачыкланган (табылган) урыннар янәшәсендәге ишегалларны һәм территорияләрне әйләнеп чыгуны (тикшерүне) башкара, үлгән хайваннарны исәпкә алуны алып бара.

Ветеринария разведкасы төркеме даими әзерлек режимында тора һәм хайваннарның үлү (авыру) очраклары турында мәгълүмат алганнан соң бер сәгать эчендә урыннарга чыга.

Ветеринария разведкасы төркеме район дәүләт ветеринария берләшмәсе хезмәткәрләреннән формалаша. Ветеринария разведкасы группасы командиры Отряд командиры урынбасары булып тора.

Ветеринария разведкасы төркеменең шәхси составы шәхси саклану костюмнары, сулыш органнарын саклау чаралары белән тәэмин ителә.

Төркемне җиһазлау: авыру хайваннарны тоту өчен кирәкле инвентарь, патологик материалны алу өчен махсус инструментлар, патологик материалны транспортлау өчен кирәк булган термоконтейнер, лабораториягә патологик материал юнәлешләре бланклары, мобиль элемтә чаралары, полиэтилен капчыклар, дезинфекция чаралары, кулларны юу өчен су салынган сыешлык (5 литрдан да ким түгел), сөлге, сабын, бинокль, фонарь, үлгән хайваннарны исәпкә алу журналы.

3.4. Малларны тоту һәм үтерү төркеме авыру хайваннарны аулый, хайваннарны кан чыгармыйча үтерә, аларны җыю һәм транспортка төяү буенча чаралар үткәрә, үлгән хайваннарны исәпкә ала.

Терлекләрне тоту һәм үтерү төркеме район ветеринария берләшмәсе, җирле үзидарә органнары, финанс органы хезмәткәрләреннән формалаша.

Төркемнең шәхси составы шәхси саклану костюмнары һәм сулыш органнарын саклау чаралары белән тәэмин ителә.

Төркемне җиһазлау: хайваннар тоту өчен кирәк-яраклар, полиэтилен капчыклар, хайваннарны үтерү өчен чаралар, шприц-автоматлар, үлгән хайваннарны исәпкә алу журналы һәм дезинфекция чаралары.

3.5 Утильләштерү төркеме утильләштерү урынын әзерли, хайван үләксәләрен утильләштерү урынына китереп бушата, дезинфекцияләү чараларын кулланып яки янгын куркынычсызлыгы чараларын төгәл үтәп,

яндыру юлы белән биотермик чокырларда хайван үләксәләрен утильләштерә, дезинфекция чараларын утильләштерелгән хайваннарны исәпкә ала.

Утильләштерү төркеме «Әлки район дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ, «Әлки коммуналь челтәрләре» ҖЧҖ, «Кызыл Шәрык-Агро» АҖнең Әлки филиалы һәм җирле үзидарә органнары хезмәткәрләреннән төзелә.

Утильләштерү төркеме составындагы ветеринария-санитария экспертизасы лабораториясенең ветеринария табибы ветеринария-санитария экспертизасы кагыйдәләре нигезендә сую (чалу) продуктларына ветеринария-санитария тикшерүе һәм ит һәм ит продуктларына ветеринария-санитария экспертизасы уздыра.

Төркемнең шәхси составы саклау костюмнары, сулыш органнарын саклау чаралары, резина перчаткалар белән тәэмин ителә.

Төркемне җиһазлау: металл кузовлы экскаватор һәм йөк автомобиле (яки металл сыешлык белән җиһазландырылган автомобиль), дезинфекция чаралары, утильләштерелгән хайваннарны исәпкә алу журналы.

3.6. Дезинфекция төркеме авыруларны ачыклау урынын механик чистарту, йогышлы авыру чыганагына агымдагы һәм йомгаклау дезинфекциясен (ветеринария дезинфекциясе, дезинвазия, дезинсекция һәм дератизация үткәрү инструкциясе нигезендә) үткәрә. Дезинфекция төркеме «Әлки район дәүләт ветеринария берләшмәсе»ДБУ хезмәткәрләре арасыннан формалаша.

Төркемнең шәхси составы саклау костюмнары, сулыш органнарын саклау чаралары, резина перчаткалар белән тәэмин ителә.

Төркемне җиһазлау: Комаровның дезинфекция җайланмасы һәм дезинфекция чаралары.

3.7. Медицина һәм эпидемиология разведкасы төркеме гамәлгә ашыра:

- эпидемия чыганагында медицина һәм санитар-эпидемиологик разведка һәм күзәтчелекне уздыру;
- авыру чыганагында яшәүче халыкка һәм риск төркеме затларына (эпизоотия учагын бетерүдә катнашкан отрядның һәм башка катнашучыларның шәхси составы) медицина каравы үткәрү;
- авыруларны ачыклау максаты белән ишегалларны йөреп чыгу (авыруга шик булганда) һәм авырулар белән аралашучыларны һәм контакт дәрәҗәсен билгеләү;
- республиканың махсуслаштырылган лабораторияләренә лаборатор тикшеренүләр өчен материалны сайлап алу һәм китерү;
- ашыгыч профилактикалау һәм ашыгыч профилактиканы оештыру һәм үткәрүне контрольдә тоту;
-авыруларны, авыруга шик булган затларны вакытлыча изоляцияләү;
- эпидемия чыганагында агымдагы һәм йомгаклау йогышсызландыруны үткәрү һәм контрольдә тоту;
- Отряд командирына разведка мәгълүматларын бирү.

Медицина һәм эпидемиология разведкасы төркеме "Базарлы Матак үзәк район хастаханәсе"ДАССОның хезмәткәрләре арасыннан формалаша.

Медицина һәм эпидемиология разведкасы төркеменең шәхси составы саклау костюмнары, сулыш органнарын саклау чаралары, резина перчаткалар белән тәэмин ителә.

Гнеденков Ю. А. 8(84346) 2-02-04

Төркемне җиһазлау: лаборатория тикшеренүләренә материал алу өчен җиһаз, табиб өчен җиһаз.

3.8. Үткәрү режимын тәэмин итү төркеме карантин зонасында хәрәкәтне оештыру һәм җайга салуны тәэмин итә. Төркем контроль-пропуск постларыннан һәм патруль-пост хезмәте постларыннан тора. Постлар саны карантин зонасына керү (чыгу) саны белән билгеләнә.

Төп керү (чыгу) урыннарында (карантин зонасында) контроль-пропуск постлары, икенчел урында – патруль-пост хезмәте постлары булдырыла.

Үткәрү режимын тәэмин итү төркеме Россия эчке эшләр министрлыгының Әлки районы буенча бүлекчәсе, Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе һәм "Әлки районы дәүләт ветеринария берләшмәсе" ДБУ хезмәткәрләре арасыннан формалаша.

Контроль-пропуск постын җиһазлау: җиңел автомобиль, мобиль элемтә чаралары, дезинфекция барьеры, шлагбаум, кешеләрнең киемнәрен алыштыру урыны, Комаровның дезинфекция җайланмасы яки транспорт чараларын юу һәм дезинфекцияләү өчен махсус техника, эшче эремә әзерләү өчен сыешлык, су өчен сыешлык, дезинфекция чаралары, юынгыч, сөлге, сабын, "Карантин" дип язылган аншлаг.

Патруль-пост хезмәте постын җиһазлау: җиңел автомобиль, мобиль элемтә чаралары, шлагбаум, "Карантин" язулы аншлаг, карантин зоналарын, әйләнеп үтүне күрсәтүче юл билгеләре, фонарь.

Үткәрү режимы төркеменең шәхси составы саклау костюмнары, сулыш органнарын саклау чаралары, итекләр, резина перчаткалар белән тәэмин ителә.

3.9. Җәмәгать тәртибен саклау төркеме карантин зонасында хокук тәртибен саклауны тәэмин итә, Отрядның шәхси составын, беренче чиратта, хайваннарны тоту һәм үтерү төркемнәрен, медицина һәм эпидемиология разведкасы төркемнәрен озатып баруны һәм саклауны оештыра.

Җәмәгать тәртибен саклау төркеме Россия Эчке эшләр министрлыгының Әлки районы буенча бүлекчәсе хезмәткәрләре арасыннан формалаша.

Төркемнең шәхси составы корал һәм саклану штат чаралары белән тәэмин ителә һәм җиһазландырыла.

3.10. Табиб-шәфкать туташлары бригадасы карантин-чикләү чараларын уздыру чорында халыкка кичектергесез медицина ярдәме күрсәтә, ачыкланган авыруларны йогышлы авырулар бүлегенә госпитализацияләүне оештыра.

Табиб-шәфкать туташлары бригадасы «Базарлы Матак үзәк район хастаханәсе»ДАССОның хезмәткәрләре арасыннан формалаша.

Бригаданың шәхси составы саклагыч костюмнар, халатлар, баш киеме һәм битлекләр белән тәэмин ителә.

Бригаданы җиһазлау: Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының җитәкче документлары таләпләре нигезендә табибларны урнаштыру һәм табель мөлкәте белән тәэмин итү.

3.11. Янгын расчеты үлгән хайваннарны яндырганда янгын куркынычсызлыгы чараларын үтәүне башкара.

Әлки муниципаль районының ирекле янгын сүндерү командасы шоферы яндыру урынын сайлауда катнаша. Янгын чыккан очракта аны сүндерүне оештыра һәм үткәрә.

Гнеденков Ю. А. 8(84346) 2-02-04

3.12. Санитар эшкәртү пункты шәхси составны һәм транспорт чараларын санитар эшкәртү һәм бер тапкыр кулланыла торган киемнәрне яндыру юлы белән юк итүне башкара.

Пунктның шәхси составы торак-коммуналь хуҗалык предприятиеләре хезмәткәрләреннән дә формалаша.

Хайваннар һәм кешеләр авыруларын локальләштерү һәм бетерү буенча чаралар комплексы тәмамланганнан соң, Отрядның шәхси составы һәм карантин зонасында эшкә җәлеп ителгән затлар мәҗбүри санитар эшкәртүе уза, ә бер тапкыр кулланыла торган махсус кием яндыру юлы белән юк ителә.

Пунктны җиһазлау: Комаров дезинфекцион җайланмасы (күчмә душ җайланмалары яки ранецлы дезинфекцияле сиптергечләр), су өчен сыешлык, сабын, сөлге, утын.

## 4. ОТРЯД КОМАНДИРЫ ВАЗЫЙФАЛАРЫ

4.1. Отряд командиры эпидемия учагында эпизоотиягә каршы чараларны оештыру һәм үткәрү, Отрядны шәхси составын һәм мөлкәт белән комплектлау өчен җавап бирә һәм йогышлы авырулар чыганагын бетерү буенча бурычларны үтәү чорында Отрядның барлык шәхси составының турыдан-туры башлыгы булып тора.

4.2. Отряд командиры бурычы:

- авыру чыганагында эпизоотиягә каршы чараларны оештыру һәм алып бару буенча җитәкче документларның таләпләрен белү һәм үз эшчәнлеге буенча аларга таяну;
- Отрядның урнашу һәм эш итү районнарында ветеринария-санитария һәм эпизоотик вәзгыятьне өйрәнү;
- Отрядның авыру чыганагындагы хәрәкәт әзерлеген арттыру һәм эшен камилләштерү буенча чаралар әзерләү һәм оештыру;
- ветеринария хезмәтләре белгечләренә терлекләрнең йогышлы авыру эпизоотик вәзгыяте буенча, әлеге авыруларга каршы көрәш чаралары, авыру йоктырган һәм йоктыруда шикләнелүче терлекләрнең техник куркынычсызлыгы кагыйдәләре турында мәгълүмат бирүне оештыру;
- Әлки муниципаль районының ГТХ (КЧС) һәм КТО (ОПБ) рәисе карарын эшләү өчен-карантин кертү турында тәкъдимнәр бирү;
- шәхси составны махсус әзерләүне оештыру һәм уздыру;
- Отряд бүлекчәләренең ихтыяҗларын билгеләү һәм белү;
- Отряд өчен тиешле матди һәм дезинфекция чараларын үз вакытында соратып алу;
- матди чараларны исәпкә алуны, саклауны һәм куллануны контрольдә тоту;
- Отрядның шәхси составы белән аны эпизоотик авыру чыганакларындагы хәрәкәтләргә әзерлек буенча тренировкалар үткәрү;
- Әлки муниципаль районының ГТХ һәм КТО рәисенә зонадагы эпизоотик хәл, гадәттән тыш хәлләрне бетерү турында мәгълүматларны үз вакытында тапшыру;
- Отрядның шәхси составының функциональ бурычларын эшләүдә катнашу һәм аларны раслау;

Гнеденков Ю. А. 8(84346) 2-02-04

- Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә карантинны бетерү буенча тәкъдимнәр бирү.

## 5. ОТРЯДНЫ ӘЗЕРЛЕККӘ КИТЕРҮ ТӘРТИБЕ

5.1. Отрядны сигнал алган мизгелдән үк әзерлеккә китерү өчен 2 сәгатьтән күбрәк булмаган гомуми вакыт бирелә. Шул ук вакытта ветеринария разведкасы төркеме эпизоотик чыганакка бер сәгать эчендә барып җитә.

5.2. Отрядны әзерлеккә китерү буенча барлык чаралар да, шәхси составны хәбәр итү һәм җыю һәм комплектлаштыру эпизоотик чыганакка чыгу вакытында отряд белән идарә итүне комплектлау, оештыруны да кертеп, отряд командиры карары буенча тормышка ашырыла.

5.3. Отрядның шәхси составын хәбәр итү һәм җыю өчен «Әлки район дәүләт ветеринария берләшмәсе»ДБУнә кизү тору инструкциясе әзерләнә.

5.4. Бүлекчә командирлары җыелу урынына килеп җитү белән Отряд командирына шәхси составның, автомобиль техникасының килеп җитүе һәм шәхси составның бурычларны үтәүгә әзерлеге турында хәбәр итәләр.

## 6. ОТРЯДНЫҢ ШӘХСИ СОСТАВЫН ӘЗЕРЛӘҮ

6.1. Отрядка кергән белгечләр штаттагы вазифалар буенча эшләү тәҗрибәсенә ия булырга тиеш.

6.2. Отрядның шәхси составын әзерләүнең төп методлары булып инструктор-методик дәресләр, гамәли күнекмәләр һәм өйрәнүләр тора.

Шәхси состав белән инструкторлык-методик дәресләрдә эпизоотик чыганакта эшләгәндә шәхси составның йогышлы авыруларын кисәтү, шәхси саклану чараларыннан файдалану кагыйдәләренә, шулай ук кеше һәм хайваннар өчен уртак булган аеруча куркыныч авыруларга каршы көрәш чаралары турында инструкцияләр таләпләрен һәм әлеге Нигезләмә таләпләрен җиткерүгә аерым игътибар бирелә.

Отрядның шәхси составы белән инструктор-методик дәресләрне бүлекчә командирлары үткәрә.

Күнекмәләрне әзерләү, үткәрү һәм тикшерү өчен Отряд командиры җавап бирә.

## 7. ОТРЯД ДОКУМЕНТЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ

7.1 Отрядта документларның мәҗбүри исемлеге төзелә. Документларның бер нөсхәсе - Әлки муниципаль районының ГТХ (КЧС) һәм КТО (ОПБ) рәисендә, икенчесе - Отряд командирында саклана.

7.2. Отряд документациясен алып бару, документлардагы белешмәләрне дөрес рәсмиләштерү һәм вакытында төгәлләштерү өчен Отряд командиры җавап бирә.

7.3. Отряд документлары исемлеге:

- Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының эпизоотиягә каршы даими әзерлекле җыелма мобиль отрядын төзү һәм комплектлау турында карары күчермәсе;

- Отрядның оештыру-штат структурасы;

-Отрядның микъдари составы;

- отряд составына кертелә торган автомобиль техникасы исемлеге;

- эш һәм эштән тыш очракларда төркем командирларына хәбәр итү схемасы;

- Отрядның шәхси составын хәбәр итү һәм җыю буенча «Әлки район дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУнең кизү тору инструкциясе.

Гнеденков Ю. А. 8(84346) 2-02-04

2 нче номерлы
кушымта

## *Отрядның оештыру-штат структурасы*

**Командир -1**

җиңел автомобиль -1 берәмлек.

**Ветеринария разведкасы төркеме:**
-командир (ветеринар лабораториясе мөдире) -1 кеше.
- лаборант -1 кеше.
- машина йөртүче-1 кеше.

**Кыргый хайваннар (кошлар) санын җайга салу төркеме:**
- командир-1 кеше.
- аучылар-2 кеше, шофер-1 кеше.
җиңел автомобиль -1 берәмлек.

**Читләштерү төркеме:**
- төркем командиры (табиб-эпизоотолог) - 1 кеше.
- машина йөртүче-4 кеше.
- тотучылар (ловцы)-4 кеше.
- хисапчы-1 кеше.
- ОМСУ финанс бүлеге вәкиле-1 кеше.
йөк автомобиле -4 берәмлек.

**Утильләштерү төркеме:**
- төркем командиры ( ОМСУ коммуналь хезмәте вәкиле) - 1кеше
- утильләштерүче-4 кеше.
- машина йөртүче-экскаваторчы-1 кеше.
- хисапчы-1 кеше.
-ветер.-санитар. эксперты – 1 кеше.

**Медицина һәм эпидемиология разведкасы төркеме:**
- төркем командиры (табиб-эпидемиолог яки инфекционист) - 1 кеше.
- санитар табиб-1 кеше
- фельдшер-1 кеше.
- машина йөртүче -1 кеше.
җиңел автомобиль -1 берәмлек.

**Дезинфекция төркеме:**
- командир (дезинфектор) -1 кеше.
- лаборант -1 кеше.
- дезинфектор -1 кеше.
- машина йөртүче-дезинфектор - 1 кеше.
Комаров дезинфекция җайланмасы-1 берәмлек.

**Үткәрү режимын тәэмин итү төркеме:**
- төркем командиры -4 кеше.
-көйләүче (регулировщик ) - 4 (ЮХИДИ, полиция органнары хезмәткәрләре)
- дезинфектор -4 кеше.
шофер-дезинфектор -4 кеше
патруль-пост хезмәте автомобиле -4
Комаров дезинфекция җайланмасы-4 берәмлек.

**Җәмәгать тәртибен саклау төркеме:**
- төркем командиры -1 кеше.
– Эчке эшләр органнары хезмәткәрләре (полиция) - 5 кеше.
- машина йөртүче -2 кеше.
автомобиль -2 берәмлек.

**Санитар-юдыру пункты:**
- пункт командиры (ОМСУ коммуналь хезмәте вәкиле) - 1 кеше.
-мич ягучы(кочегар) -2 кеше.
машина йөртүче -2 кеше.
Комаров дезинфекция җайланмасы-1 берәмлек.
Күчмә душ җайланмасы-1 берәмлек.

**Табиб-шәфкать туташлары бригадасы:**
- бригада командиры (табиб)-1 кеше.
- фельдшер-1 кеше.
-шәфкать туташы -1 кеше.
- машина йөртүче -1 кеше.
санитар автомобиле-1

**Янгын расчеты:**
- исәплəү командиры -1 кеше.

- янгын сүндерүчеләр-3 кеше.

Техника:
АЦ -1 бер.

**Барлыгы: шәхси состав-49 кеше һәм аннан күбрәк, техника-17 берәмлек һәм аннан күбрәк.**

Гнеденков Ю. А. 8(84346) 2-02-

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы Башкарма
комитетының 20____ елның
____ _______________ _______ № Карарына
3 нче Кушымта

## Төркем составы

| т/б № | Оешма исеме | Бүлеп бирелә торган кешеләр саны, кеше | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| 1 | "Әлки район дәүләт ветеринария берләшмәсе" ДБУ | 17 | Нигезендә Оештыру-штат төзелеш (2 нче кушымта ) |
| 2 | "Базарлы Матак үзәк район хастаханәсе" ДАСУ | 7 | |
| 3 | Россия Эчке эшләр министрлыгының Әлки районы буенча бүлекчәсе | 10 | |
| 4 | ТР буенча 7 нче ФПС отряды «ФГКУ 105 нче янгын сүндерү бүлеге» | 3 | |
| 5 | «Татарстан Республикасы (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең Нурлат районы филиалы. | 1 | |
| 6 | "Әлки коммуналь челтәрләре" ЖЧЖ | 4 | |
| 7 | Әлки филиалы "Кызыл Шәрыкъ Агро" АЖ | 7 | |
| | Барлыгы | 49 | |

Гнеденков Ю. А. 8(84346) 2-02-04


Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы  Башкарма
комитетының  20____  елның
____ ______________ _______ № Карарына
4 нче Кушымта

**Отряд**
**составына кертелгән техника исемлеге**

| №<br>т/б | Автомобиль  һәм махсус техника төре | Техника саны, берәмлек | Техника бирелә<br>(оешманың исеме) |
|---|---|---|---|
| 1. | Җиңел автомобиль | 4 | "Әлки районы<br>ветеринария берләшмәсе»ДБУ |
| | | 3 | Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Әлки районы бүлекчәсе |
| | | 1 | "Әлки коммуналь челтәрләре" ҖЧҖ |
| | | 2 | «Базарлы Матак үзәк район хастаханәсе " ДАУЗ |
| 2. | Йөк автомобиле | 1 | "Әлки коммуналь челтәрләре" ҖЧҖ |
| | | 1 | Әлки филиалы<br>"Кызыл Шәрыкъ Агро" АҖ |
| 3. | Автоцистерна | **1** | Әлки филиалы<br>"Кызыл Шәрыкъ Агро" АҖ |
| 4. | Экскаватор | **1** | Әлки филиалы<br>"Кызыл Шәрыкъ Агро" АҖ |
| 5. | гын сүндерү машинасы | **1** | ТР буенча 7 нче ФПС отряды «ФГКУ 105 нче янгын сүндерү бүлеге» |
| 6. | АЗ-3309 шассиларына У-2 зинфекция җайланмасы | **1** | "Әлки районы<br>ветеринария берләшмәсе»ДБУ |
| | Күчмә дезинфекция җайланмасы | **1** | |
| | **Барлыгы** | **17** | |

Гнеденков Ю. А. 8(84346) 2-02-04

## *Шәхси составка хәбәр итү схемасы*




**20____ елның ____ ___________ анықланган.**

**Отряд командиры** ______________________________

*Искәрмә * - бүлекчә командирлары хәбәр итү схемасы буенча шәхси составка хәбәр итәләр.*

Гнеденков Ю. А. 8(84346) 2-02-04

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы Башкарма
комитетының 20____ елның
____ _____________ ______ № Карарына
6 нчы Кушымта

"Әлки район дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ отрядның шәхси составын хәбәр итү һәм җыю буенча кизү тору инструкциясе

**1. Отрядның шәхси составын хәбәр итү һәм җыю отряд командиры, муниципаль берәмлек башкарма комитеты җитәкчесе карары буенча башкарыла ала.**

2.Дәүләт ветеринария берләшмәсендә кизү торучы Отрядның шәхси составын хәбәр итүгә һәм шәхси составын җыюга команда (боерык) алганда, алынган мәгълүматның датасын һәм вакытын, мәгълүматны тапшыручының фамилиясе, исеме, әтисенең исемен, кыскача эчтәлеген, контакт телефоны номерын журналда теркәргә тиеш.

3.Кизү торучы отрядның шәхси составына телефон аша билгеләнгән схема буенча хәбәр итә.

***Отряд командиры _____________К. Ш. Хәйруллин***

Гнеденков Ю. А. 8(84346) 2-02-04